МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ ____1075/о______

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«___23__»_______07_______2025__

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ «ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ ӨЛКӘСЕ ТЕМАЛАРЫН АЕРУЧА ЯХШЫ ЯКТЫРТУ БУЕНЧА МАССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫНЫҢ ЕЛ САЕН УЗДЫРЫЛА ТОРГАН КОНКУРСЫН ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ РАСЛАУ ТУРЫНДА» 2021 ЕЛНЫҢ 23 ИЮЛЕНДӘГЕ 117/О НОМЕРЛЫ БОЕРЫГЫ БЕЛӘН РАСЛАНГАН ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ ӨЛКӘСЕ ТЕМАЛАРЫН АЕРУЧА ЯХШЫ ЯКТЫРТУ БУЕНЧА МАССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫНЫҢ ЕЛ САЕН УЗДЫРЫЛА ТОРГАН КОНКУРСЫН ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘГӘ ҮЗГӘРЕШ КЕРТҮ ХАКЫНДА

Массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең Татарстан Республикасында төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы мәсьәләләрен һәр яклап һәм объектив яктыртуга кызыксынуына этәргеч бирү максатларында

**Боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсе темаларын аеруча яхшы яктырту буенча массакүләм мәгълүмат чараларының ел саен уздырыла торган конкурсын үткәрү турында нигезләмә раслау турында» 2021 елның 23 июлендәге 117/о

номерлы боерыгы (2022 елның 27 июлендәге 78/о номерлы, 2023 елның 1 августындагы 123/о номерлы, 2024 елның 6 августындагы 253/о номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсе темаларын аеруча яхшы яктырту буенча массакүләм мәгълүмат чараларының ел саен уздырыла торган конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бирергә (кушымтада бирелә).

2. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Җ.Зәйнуллинага) бу боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынган вакыттан ун эш көне эчендә аның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр М.М. Айзатуллин

Отдел контроля исполнения документов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ,
АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ
23.07.2021 ЕЛ, № 117/О БОЕРЫГЫ БЕЛӘН
РАСЛАНДЫ (ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ,
АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ
« 23 « _07_2025 ЕЛ, № 1075/О БОЕРЫГЫ
РЕДАКЦИЯСЕНДӘ)

## Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсе темаларын аеруча яхшы яктырткан өчен массакүләм мәгълүмат чараларының ел саен уздырыла торган конкурсын үткәрү турында нигезләмә

### 1. Төп нигезләмәләр

1.1. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсе темаларын аеруча яхшы яктырту буенча массакүләм мәгълүмат чараларының ел саен уздырыла торган конкурсын үткәрү турында әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, конкурс) конкурсны оештыру һәм уздыру тәртибен билгели.

1.2. Конкурс елга бер тапкыр Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан үткәрелә.

1.3. Конкурста законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән аерым авторлар, авторлык коллективлары, массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре (алга таба – ММЧ редакцияләре) катнаша ала.

1.4. Конкурста катнашуга «Чит ил йогынтысында булган затларның эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә ММЧ редакцияләре яисә чит ил агенты статусына ия аерым авторлар кертелми.

1.5. Конкурска алдагы елның октябреннән башлап быелның сентябренә кадәр массакүләм мәгълүмат чараларында (алга таба – ММЧ) басылып чыккан яки эфирга чыгарылган, Татарстан Республикасында төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы темаларын яктырта торган мәкаләләр, телевидение сюжетлары, мәгълүмати, аналитик һәм яңалык материаллары кабул ителә.

1.6. Конкурсны уздыруны һәм аңа йомгак ясауны оештыру өчен кимендә 10 кешедән торган оештыру комитеты (алга таба — Оештыру комитеты) төзелә. Оештыру комитеты составына рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм Оештыру комитеты әгъзалары керә. Оештыру комитеты Министрлык вәкилләреннән һәм Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкиленнән төзелә (килешү буенча). Оештыру комитеты үз эшен түләүсез нигездә башкара.

Оештыру комитетының составы Министрлык боерыгы белән раслана.

1.7. Оештыру комитеты эшенә рәис җитәкчелек итә. Оештыру комитеты рәисе булмый торганда, рәис вазыйфалары Оештыру комитеты рәисе урынбасарына йөкләнә.

1.8. Оештыру комитеты секретаре түбәндәге функцияләрне башкара:

Оештыру комитеты эшчәнлек алып бара;

Оештыру комитетына кергән конкурс эшләрен кабул итә һәм терки һәм аларны Оештыру комитеты утырышында карау өчен әзерли;

Оештыру комитеты утырышын оештыра һәм беркетмә төзи.

Оештыру комитеты секретаре Оештыру комитеты әгъзалары составына керми һәм аның утырышларында тавыш бирмичә генә катнаша.

## 2. Конкурс номинацияләре

Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә, аларның һәрберсендә 1 урынны алган җиңүчеләр һәм 2 һәм 3 урынны алган призерлар билгеләнә:

«Шәһәр мохите» (ишегалларын, паркларны һәм скверларны төзекләндерү, шул исәптән Татарстан Республикасында республика һәм федераль программаларны гамәлгә ашыру турында);

«Тормыш сыйфаты» (Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә, социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларга капиталь ремонт ясау турында);

«Торак күчемсез мөлкәт» (торак төзелеше, ипотека кредитлау базарын үстерү, Татарстан Республикасында торак сатып алу ысуллары һәм программалары турында);

«Социаль инфраструктура» (социаль инфраструктура объектларын төзү турында: Татарстан Республикасында мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, спорт, яшьләр сәясәте объектлары);

«ТКХ фокусында» (Татарстан Республикасында коммуналь инфраструктураны модернизацияләү, торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү турында);

«Үз эшенең профессионаллары» (Татарстан Республикасы төзелеш тармагы һәм торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсе хезмәткәрләре эшчәнлеге турында);

«Темага тугрылык» махсус номинациясе (төзелеш һәм капиталь ремонт буенча федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру өлешендә Министрлык эшчәнлегенә актив мәгълүмати ярдәм күрсәткән өчен Оештыру комитеты карары белән бер җиңүче билгеләнә).

## 3. Конкурста катнашу тәртибе һәм шартлары

3.1. Конкурста катнашу гариза һәм конкурс эшләрен PDF форматында Оештыру комитеты адресына рус һәм татар телләрендә Министрлыкның электрон почтасына җибәрү юлы белән башкарыла: pressa.msagkh@mail.ru.

Конкурста катнашу өчен гариза әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча гариза тутыру юлы белән бирелә.

Конкурста катнашу өчен гаризада шулай ук түбәндәгеләр була:

а) юридик затлар сыйфатында теркәлгән ММЧ редакцияләре өчен:

салым органында юридик затны исәпкә кую турында таныклык (салым түләүченең идентификация номеры) (күчермә);

гамәлгә кую документлары (күчермә);

ММЧ теркәү турында таныклык (күчермә) яисә теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә (күчермә);

б) юридик зат буларак оештырылмаган ММЧ редакцияләре өчен:

ММЧ теркәү турында таныклык (күчермә) яисә теркәлгән ММЧ реестрыннан өземтә (күчермә);

ММЧ редакциясенең уставы яисә «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 20 статьясы нигезендә аны алмаштыра торган килешү күчермәсе, әгәр ММЧ редакциясендә 10 кешедән азрак булса;

в) физик затлар (авторлар, авторлык коллективлары) өчен:

әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы нигезендә киңәш ителә торган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасы нигезендә киңәш ителә торган форма буенча ризалык;

г) җиңүчеләр һәм призерлар өчен:

салым түләүче тарафыннан (җыемнар, иминият кертемнәре, салым агенты тарафыннан) салым, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурыч үтәлеше турында белешмә.

Конкурста катнашучы булып ММЧ редакциясе торса, документларның күчермәләре, тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләр булган очракта (законнар нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе күчермәсен теркәп), конкурста катнашучының җитәкчесе яки башка вәкаләтле зат тарафыннан таныклана.

Электрон почта аша бирү мөмкинлеге булмаса, гариза һәм конкурс эше Министрлыкның почта адресына, «ММЧ конкурсы» тамгасы белән, электрон рәвештә яки кәгазьдә җибәрелә ала: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Дзержинский урамы, 10 йорт, 215 кабинет.

3.2. Гаризалар Министрлыкта аларны мөрәҗәгать итүчедән алганнан соң бер эш көне эчендә теркәлә.

3.3. Конкурста катнашучылар үз эшләрен берничә номинациядә катнашу өчен, һәр номинация буенча 3 эшкә кадәр тәкъдим итә алалар, әмма бөтен Конкурс өчен 5 эштән артык була алмый.

3.4. «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлегенә контроль турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә югарыда санап үтелгән материалларны бастырып чыгаруга юнәлдерелгән яисә чит ил агенты статусына ия булган фәнни-методик мәкаләләр, закон һәм норматив хокукый актларга аңлатма шәрехләр, фәнни автор тикшеренүләре, методик эшләнмәләр, шулай ук басмалар конкурста катнашуга кертелми.

3.5. Конкурска тапшырыла торган материаллар түбәндәге таләпләргә

туры килергә тиеш:

3.5.1. Аудиоматериаллар:

а) форматы – MP3;

б) тавыш сыйфаты – битрейты кимендә 128 Кбит/с;

в) файлның күләме – иң күбе 30 Мб.

3.5.2. Видеоматериаллар:

а) форматы – AVI, MPEG-1, MPEG-2, MPEG-4;

б) файлның күләме – иң күбе 300 Мб;

в) тавыш сыйфаты – битрейты кимендә 128 Кбит/с;

г) видеоның сыйфаты – кимендә 720×576 пиксель;

д) кадрлар ешлыгы – 25 кадр/с.

3.5.3. Текстлы мәкаләләр:

а) басма матбугатлар өчен – PDF форматы (А4 форматындагы 2 биттән яисә А3 форматындагы 1 биттән башлап, фотолар белән);

б) интернет-басмалар өчен аралыклы 6000 билге.

3.6. Өченче затларның авторлык хокукларын үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә конкурска материаллар тапшырган мөрәҗәгать итүче җавап тота.

## 4. Конкурс эшләрен конкурста катнашуга кертү критерийлары

4.1. Оештыру комитеты гаризаны теркәгәннән соң өч эш көне эчендә әлеге Нигезләмәнең 1.3, 1.4, 3.1, 3.4, 3.5, 5.1 пунктларында бәян ителгән таләпләргә туры килү-килмәве буенча конкурс эшләрен бәяләү нәтиҗәләре буенча конкурста катнашуга кертү яки кертүдән баш тарту турында карар кабул итә.

4.2. Мондый карар кабул ителгән көннән башлап өч эш көне эчендә, кулга тапшыру турында белдереп, мөрәҗәгать итүчеләргә конкурста катнашуга кертүдән баш тарту турында заказлы хат белән яисә электрон почтага хат җибәрү юлы белән хәбәр ителә.

4.3. Конкурста катнашуга кертелмәгән эшләр, җитешсезлекләре бетерелгәннән соң, конкурска документлар тапшыру өчен билгеләнгән срокларда кабат тапшырылырга мөмкин.

## 5. Конкурсны үткәрү вакыты һәм тәртибе

5.1. Конкурста катнашу өчен гаризалар быелның 1 сентябреннән 30 сентябренә кадәр (кабул итүнең соңгы көне) кабул ителә. Конкурс бер этапта үткәрелә.

5.2. Конкурс үткәрү турында мәгълүмат, әлеге Нигезләмәнең 5.16 пунктын исәпкә алып, номинацияләр буенча акчалата бүләк күләмен дә кертеп, гаризалар һәм конкурс эшләре кабул ителә башлаганчы кимендә өч көн алдан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

5.3. Оештыру комитеты, утырышта аның составының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, карарлар кабул итәргә хокуклы.

5.4. Конкурска кертелгән конкурс эшләрен бәяләү Оештыру

комитетының утырышта катнашкан әгъзалары тарафыннан өч критерий буенча бәяләнә, алар буенча баллар саны 5 баллы шкала (0 башлап 5 кадәр) буенча билгеләнә:

материалда күрсәтелгән проблематиканың объективлыгы һәм актуальлеге, теманы ачуның тулылыгы (0 баллдан 5 баллга кадәр);

бәян итүнең конкрет, анык, эчтәлекле һәм аңлаешлы булуы (0-5 балл);

тел мәдәнияте, стилистика, иҗади якын килү һәм башкару сәнгатьлелеге (0-5 балл).

5.5. Һәр катнашучы буенча ахыргы бәя Оештыру комитеты әгъзалары тарафыннан бирелгән барлык балларның арифметик уртасын ачыклау юлы белән формалаштырыла.

5.6. Оештыру комитеты карары белән бер номинация буенча иң күп балл җыйган катнашучылар әлеге номинациядә конкурста җиңүче һәм призер дип таныла.

5.7. Баллар тигез булганда, Оештыру комитеты рәисенең тавышы хәлиткеч була.

5.8. Оештыру комитеты карары йомгаклау беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, аңа Оештыру комитетының утырышта катнашкан әгъзалары имза сала һәм Оештыру комитеты рәисе, утырыштан соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көнлек срокта, ләкин 5.12 п. күрсәтелгән сроктан да соңга калмыйча, раслый.

5.9. Номинацияләрнең берсенә бер гариза бирелгән яисә бер генә гариза да бирелмәгән очракларда, әгәр Оештыру комитеты тарафыннан нинди дә булса номинация буенча «җиңүче» һәм «призерлар» исемен бирмәү турында еарар кабул ителгән булса яисә катнашучыларның берсе дә әлеге номинация буенча бер балл да җыймаган очракта, әлеге номинациядә конкурс узмаган дип танылa, ә әлеге номинациядәге премиягә бүлеп бирелгән акчалар башка номинацияләрдә билгеләнгән җиңүчеләргә тигез өлешләрдә бүленә.

5.10. Оештыру комитеты карары ахыргы карар булып тора һәм яңадан каралырга тиеш түгел.

5.11. Конкурс нәтиҗәләре Оештыру комитеты тарафыннан быелның 30 ноябреннән дә соңга калмыйча ясала.

5.12. Конкурс нәтиҗәләре Министрлыкның рәсми сайтында йомгаклау беркетмәсе имзаланганнан соң бер эш көне эчендә урнаштырыла.

Конкурста җиңүчеләргә һәм призерларга бүләкләү тантанасының урыны һәм вакыты турында ун календарь көн эчендә телефон аша өстәмә рәвештә хәбәр ителә.

5.13. Җиңү яулаган очракта, конкурста катнашучы конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында бастырылган вакыттан башлап биш календарь көне эчендә Оештыру комитетына әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасындагы форма буенча, әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән ысуллар белән белешмәләр тапшыра.

5.14. Җиңүчеләр һәм призерлар махсус дипломнар һәм акчалата бүләкләүләр белән билгеләп үтелә.

5.15. Конкурста җиңүчеләрнең һәм призерларның барысына да

Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла торган программаларны мәгълүмати-пропаганда белән тәэмин итүгә Министрлык сметасында шул максатлар өчен каралган акча чикләрендә акчалата бүләкләүләр күчерелә. Акчалата бүләкләүләр суммасы Оештыру комитетының йомгаклау беркетмәсе белән раслана.

5.16. Конкурста җиңүче тарафыннан анкетада күрсәтелгән кредит оешмалары счетларына акча күчерү Оештыру комитеты карары һәм әлеге Нигезләмә нигезендә быелның 31 декабреннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

6. Башка шартлар, элемтә өчен мәгълүмат

6.1. Конкурста катнашып, катнашучы конкурсның барлык шартлары белән ризалашуы турында раслый, шул исәптән, конкурста җиңгән очракта, аның җиңү яулау факты турындагы мәгълүматның, фамилиясенең, инициалларының, яшәү пунктының, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында да, басылып чыгуын раслый.

6.2. Конкурсны уздыру мәсьәләләре буенча аңлатмалар һәм консультацияләр оештыручы тарафыннан pressa.msagkh@mail.ru электрон почтасы буенча һәм (843) 231-14-51, (843) 231-15-00 телефоннары буенча (эш көннәрендә Мәскәү вакыты белән 10.00-17.00 сәгатьләрдә, төшке аш: 12.00-12.45 кадәр) гамәлгә ашырыла.

6.3. Конкурста катнашуга кертелгәннән соң «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлегенә контроль турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә чит ил агенты дип танылган катнашучы махсус диплом һәм акчалата приз белән бүләкләнми.

ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ ӨЛКӘСЕ ТЕМАЛАРЫН АЕРУЧА ЯХШЫ ЯКТЫРТУ БУЕНЧА МАССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫНЫҢ ЕЛ САЕН УЗДЫРЫЛА ТОРГАН КОНКУРСЫН ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘГӘ 1 НЧЕ КУШЫМТА

Үрнәк

Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсе темаларын аеруча яхшы яктырткан өчен массакүләм мәгълүмат чараларының ел саен уздырыла торган конкурсында катнашу өчен

ГАРИЗА

Әлеге эш ______________________________________________
номинациясендә төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсе темаларын аеруча яхшы яктырту буенча ел саен уздырыла торган массакүләм мәгълүмат чаралары конкурсында катнашу буенча тапшырылды

Эшнең исеме ________________________________________________

Материалның чыгу датасы

________________________________________

Билгеләр саны (интернет басмалары өчен)__________________________

Автор турында мәгълүматлар:

Авторның Ф.И.А. (ата исеме – булган очракта) яисә коллективның исеме

____________________________________________________

Вазыйфа ____________________________________________

Тәкъдим ителә торган ММЧ

______________________________________

Редакциянең адресы (индекс белән) һәм телефоны (шәһәр/торак пункт коды белән)

____________________________________________

Автор белән элемтәгә керү өчен координаталар:

Элемтә телефоны (хезмәт һәм мобиль) __________________

Электрон почта адресы (E-mail) ____________________________

Хәзергесе белән раслыйм:

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлегенә контроль турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә чит ил агенты булып саналмыйм;

авторлык коллективы әгъзалары арасында «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлегенә контроль турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә чит ил агенты дип танылган затлар юк.

«____»_________ 20___ел.  
Төзү датасы

______________________  
Катнашучының имзасы

ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ ӨЛКӘСЕ ТЕМАЛАРЫН АЕРУЧА ЯХШЫ ЯКТЫРТКАН ӨЧЕН МАССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫНЫҢ ЕЛ САЕН УЗДЫРЫЛА ТОРГАН КОНКУРСЫН ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘГӘ
2 НЧЕ КУШЫМТА

Үрнәк

Акчалата бүләк күчерү өчен, төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсе темаларын аеруча яхшы яктырту буенча массакүләм мәгълүмат чаралары конкурсында җиңүче (призер) анкетасы

Физик затлар (авторлар, авторлык коллективлары) паспорт (паспортлар) күчермәсен, ИНН күчермәсен, иминият таныклыгы күчермәсен тапшыра һәм банк счеты реквизитларын күрсәтә:
Банкның исеме/адресы ____
Банкның ИНН/КПП _____
Банкның БИК _____
Банкның корреспондент счеты ____
Банк картасының исәп-хисап счеты номеры (20 билге) ____
Банк картасы номеры (16 билге)_____

Юридик затлар (юридик зат буларак оештырылмаган массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре) банк счеты реквизитларын тапшыра: Банк атамасы-адресы _____
Банкның адресы _________
Банкның БИК

_____
Банкның ИНН/КПП

_____
Банкның корреспондент счеты ______Исәп-хисап счеты ______

«__»_________20__ ел.

_________________
Төзү датасы Имза

ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ ӨЛКӘСЕ ТЕМАЛАРЫН АЕРУЧА ЯХШЫ ЯКТЫРТКАН ӨЧЕН МАССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫНЫҢ ЕЛ САЕН УЗДЫРЫЛА ТОРГАН КОНКУРСЫН ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘГӘ
3 НЧЕ КУШЫМТА

Киңәш ителә торган рәвеше

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә темаларны иң яхшы яктыртуга массакүләм мәгълүмат чаралары конкурсында катнашу максатында, шәхси мәгълүматларымы эшкәртүгә риза (аларны миннән һәм/яисә теләсә кайсы өченче затлардан алуны да кертеп) «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон таләпләрен түбәндәге күләмдә исәпкә алып:

| | |
|---|---|
| Эшкәртелә торган шәхси мәгълүматлар исемлеге | фамилия, исем, ата исеме (булган очракта), гражданлык, туу датасы, телефон, җенес, паспорт мәгълүматлары (бирү датасы һәм кем тарафыннан бирелгән, бүлекчә коды, теркәлү адресы), РФ субъекты, теркәлү урыны һәм фактта яшәү адресы, индекс, СНИЛС, ИНН, биләгән вазыйфа, банк счеты реквизитлары. |

Әлеге ризалык 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны гаризаны канцеляриягә яки кабул итү оешмасына, почта корреспонденциясе (хәбәрле заказлы хат) яисә мөрәҗәгатьне алу датасын раслап, электрон рәвештә алырга мөмкин.

«___» _________ 20__ел.

__________/____________________

Төзү датасы ИМЗА Тулы имза

ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ ӨЛКӘСЕ ТЕМАЛАРЫН АЕРУЧА ЯХШЫ ЯКТЫРТКАН ӨЧЕН МАССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫНЫҢ ЕЛ САЕН УЗДЫРЫЛА ТОРГАН КОНКУРСЫН ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘГӘ 4 НЧЕ КУШЫМТА

Киңәш ителә торган рәвеше

Шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның $10^1$ статьясы таләпләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсе темаларын аеруча яхшы яктырткан өчен массакүләм мәгълүмат чараларының ел саен уздырыла торган конкурсында катнашу максатында үземнең шәхси мәгълүматларымның таратылуына (тапшырылуына, бирелүенә) риза.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган шәхси мәгълүматлар категорияләре һәм исемлеге:

| т/с | Шәхси мәгълүматлар | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | ӘЙЕ | ЮК |
| Гомуми шәхси мәгълүматлар | | | |
| 1 | Фамилия | | |
| 2 | Исем | | |
| 3 | Ата исеме (булган очракта) | | |
| 4 | Туган ел, ай, дата һәм туу урыны | | |
| 5 | Адрес, телефон номеры, электрон почта адресы | | |
| 6 | Белеме | | |
| 7 | Һөнәр | | |

Эшкәртү өчен шартлар һәм тыю билгеләнә торган шәхси мәгълүматларның категорияләре һәм исемлеге

| т/с | Шәхси мәгълүматлар | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| 1. (Шәхси мәгълүматлар категориясе) | | |
| 1. | (Шәхси мәгълүматлар исемлеге) | |

Искәрмә. Әлеге юл шәхси мәгълүматлар субъектының ихтыяры буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүче оператор ягыннан чикләүләрсез тутырыла.
Шартлар һәм тыюлар затларның чикләнмәгән яки чикләнгән даирәсенә шәхси мәгълүматларны тарату һәм (яки) бирү буенча оператор башкара торган гамәлләрне чикләү яки тыюны күздә тота.
Ризалыкта өстәмә рәвештә шәхси мәгълүматларны эшкәртә торган оператор тарафыннан алынган шәхси мәгълүматларның бары тик аның катгый билгеләнгән хезмәткәрләр өчен генә мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге тәэмин ителгән эчке челтәре аша гына яисә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып тапшырыла алуы яки алынган шәхси мәгълүматларның тапшырылмау шартлары күрсәтелә ала.

Оператор-оешма турында белешмәләр: Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, 420111, Казан, Дзержинский ур., 10 йорт, салым түләүченең идентификация номеры - 1654022967

Шәхси мәгълүматлар субъектының шәхси мәгълүматлары оператор тарафыннан затларның чикләнмәгән даирәсенә тапшырылачак һәм алар белән башка төрле гамәлләр кылыначак мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: http://minstroy.tatarstan.ru/.

Әлеге ризалык 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә.

«___»________ 20__ел.

____________/______________________

Төзү датасы ИМЗА Тулы имза